

2 июльдә Ләмберә районы Аксёново авылында гаять зур масштабта XII Ботенроссия авыл Сабантуе узды. Бәйрәмдә ботен Россиядән бик кvп кунаклар катнашты, шулай ук Мордовия Республикасынын барлык районнары мәдәният хезмәткәрләре vз мәдәниятләрен тәкъдим итте. Бәйрәм кунакларын торле милләтләрнен гореф-гадәтләре, конкvреше, милли киемнәре, борынгы музыкаль инструментлары һәм әлбәттә, тәмле һәм торле традицион ризыклары белән таныштырды.      Һәрбер район белән берррәттән, Рузаевка районы Татар Пишләсе клубы хезмәткәрләре һәм ижат коллективлары Сабантуйда актив катнаштылар һәм татар мәдәниятын лаеклы тәкъдим иттеләр. Мәсәлән, «Фестивальләр фестивале» сәхнәсендә «Авылым тавышлары» Беренче тобәкара татар жыры фестиваль-конкурсында «Матур кызлар» вокаль ансамбле олылар категориясендә II дәрәжә лауреат булды, ә «Йолдызчыклар» вокаль ансамбле балалар категориясендә III дәрәжә лауреат булды. Ансамбль житәкчесе Н.А.Чалдаева.